КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 июль г.Казань № 620

Муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларны (паркларын) һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парклар (парклары) һәм сәнәгать мәйданчыкларын оештыру һәм үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру, шулай ук муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларны (паркларын) һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларны (паркларын) һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 31 июль, 620 нче
карары белән расланды

**Муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларны (паркларын) һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парклар (парклары) һәм сәнәгать мәйданчыкларын оештыру һәм үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру кысаларында муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларны (паркларын) һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Субсидияләр бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елында Министрлыкка ирештерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидия бирү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрен сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр була:

муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм/яки сәнәгать мәйданчыгы территориясендә җитештерү эшчәнлеген башлап җибәргән һәм теркәлгән кимендә ике резидент булу;

муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм/яки сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшчеләр саны – кимендә 20 кеше;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегендә муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм/яки сәнәгать мәйданчыгы эшен оештыру буенча бүлекчә (бүлек) булу.

5. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетына субсидия бирү муниципаль норматив хокук акты белән чыгым йөкләмәләрен билгеләү, бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максат нигезендә Татарстан Республикасы

бюджетыннан субсидия бирелә торган финанслашу шартлары үтәлгәндә гамәлгә ашырыла.

6. Муниципаль районны финанслашу муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларны (паркларын) һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидия күләменнән 1 процент буларак билгеләнә.

7. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең (эффекттивлыгының) максатчан күрсәткече – үткән елның хисап чорына карата муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парк (парκы) һәм/яки сәнәгать мәйданчыгы территориясендә теркәлгән резидентлар саны арту.

8. Субсидия алу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

Министрлык раслый торган форма буенча субсидия бирүгә гариза;

муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркның (паркының) һәм/яки сәнәгать мәйданчыгының гамәлгә кую документлары күчермәләрен;

муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркны (паркын) һәм/яки сәнәгать мәйданчыгын карап тотуга бәйле эшләрне гамәлгә ашыру өчен финанс ихтыяҗына нигезләүне һәм аның исәп-хисабын.

Документлар Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан кәгазь һәм электрон чыганакларда кертелә.

9. Министрлык:

субсидия бирүгә гаризаны кабул ителгән көнне гаризаларны теркәүгә алу журналында терки;

гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

тапшырылган документлар, алардагы мәгълүматлар бу Тәртип белән каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәү;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегенә бу турыда хәбәрнамә җибәрә.

11. Субсидияләр Министрлык һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге арасында төзелә торган килешү (алга таба – Килешү) нигезендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелә.

12. Килешүдә түбәндәгеләр күздә тотыла:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм/яки сәнәгать мәйданчыгы исеме;

субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләре мәгънәләре;

субсидия күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләренә ирешү һәм субсидияләрдән файдалану турында хисап бирү вакытлары һәм формалары;

субсидия алучы тарафыннан субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән максатчан күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

субсидия алучы тарафыннан Килешү һәм бу Тәртип белән каралган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тоту тәртибе;

Килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

13. Татарстан Республикасының һәр муниципаль берәмлегенә субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$C = P_1 + P_2 + P_3 + \ldots + P_n,$$

монда:

С – субсидия күләме;

$P_1$, $P_2$, $P_3$, …, $P_n$ – тәңгәл (бер төрле) товарларның, эшләр башкаруның, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән аларны җитештерүче оешмаларда товарларга, эшләр башкаруга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләр турындагы, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта («Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне җитештерүчеләрнең һәм алар белән тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт булган базар бәяләрен чагыштыру (базарга анализ ясау) ысулы белән билгеләнә торган һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатны үтәүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрү чыгымнары.

14. Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә имза кую өчен килешү проектын Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегенә җибәрә.

15. Министрлык Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегеннән имзаланган Килешүне алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә Килешүгә кул куя.

16. Субсидияләр Килешүгә Министрлык кул куйганнан соң эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетына Министрлык тарафыннан Федераль казначылыкның территориаль органында ачылган шәхси исәп-хисапка күчерелә. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтүгә бәйле булган очракларда, субсидияләр Россия Федерациясенең сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнары нигезендә төзелгән контрактны (шартнамәне) керткән көннән эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә Килешү нигезендә бирелә.

17. Субсидия алучы Министрлыкка субсидиядән файдалану турындагы хисапны Килешү һәм бу Тәртип белән каралган форма, вакытлар һәм тәртип нигезендә кертергә тиеш.

18. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Килешүдә билгеләнгән субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткече мәгънәләрен һәм план елын тәмамлау йомгаклары буенча фактта ирешелгән субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткече мәгънәләрен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

19. Субсидия алучы тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидиядән максатчан файдаланмавы өчен Россия Федерацисе законнары нигезендә җавап бирә.

20. Агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган субсидияләр агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләргә ихтыяҗ булу турындагы һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән килештерелгән карары нигезендә, әлеге субсидиянең калган өлешеннән артыграк булмаган күләмдәге акча агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетының әлеге субсидия бирү максатларына туры килә торган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен бирелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты керемена кире кайтарылырга мөмкин.

Субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемена күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты керемена Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелергә тиеш.

21. Министрлык һәм Татарстан Республикасының дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары Килешү һәм бу Тәртип белән билгеләнгән субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

22. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан субсидия максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет турындагы законнары белән күздә тотылган мәҗбүри түләттерү чаралары кулланыла.

23. Субсидияләрдән максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.